


Ничек?
Кайчан?
Кая?
Кайда?
Нигә?
Эш яки хәлнең билгесен белдерә
РӘВЕШ
Билгенең билгесен дә белдерергә мөмкин


Җөмләдә хәл, аергыч, хәбәр була
Дәрәҗә белдерә ала
РӘВЕШ
Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре
Саф рәвешләр
Күләм-чама рәвешләре
Охшату-чагыштыру рәвешләре
Вакыт рәвешләре
Урын рәвешләре
Сәбәп-максат рәвешләре

**Саф рәвешләр** эшнең сыйфатын белдерә: *берьюлы, кинәт,берәм-сәрәм, әкрен-әкрен, яланаяк, яланбаш, яланөс, аягүрә,бертавыштын, бушлай, йөзтүбән*


**Күләм –чама рәвешләре** эш яки билгенең күләмен күрсәтә: *бөтенләй, шактый, гаять, ифрат, бииһая, галәмәт, байтак, беркадәр*

**Охшату-чагыштыру рәвешләре** эшнең үтәлү ысулын яки рәвешен белдерә: *көмештәй, яшьләрчә, уттай, сөйләгәнчә, безнеңчә*

**Вакыт рәвешләре** эш яки хәлнең үтәлү вакытын белдерә: *көзен, башта, соң, аннары, өченчекөн, берсекөнгә, һәрчак, көнозын*

**Урын рәвешләре** эш яки хәлнең үтәлү урынын һәм юнәлешен белдерә: *ерак, түбән, анда, ары, якын,бире, янәшә, югарыда, түбәнтен*

**Сәбәп-максат рәвешләре** эш яки хәлнең үтәлү максатын яки сәбәбен белдерә: *юкка, тикмәгә, юри, тиктомалга, заяга, юктан, юрамалый.*


ТАМЫР
ТЕЗМӘ
КУШМА
РӘВЕШЛӘР НЕҢ ЯСАЛЫШЫ
ЯСАЛМА
ПАРЛЫ

**Тамыр рәвешләр**: *тиз, әкрен, җәяү, аз*

**Ясалма рәвешләр:** *акчалата, кышын, бушлай, башта, татарча, аюдай*

**Кушма рәвешләр:** *бераз, берьюлы, берникадәр, яланбаш, көнозын,бертавыштан, йөзтүбән, һичөзлексез*

**Парлы рәвешләр:** *аз-маз, иртә-кич, арлы-бирле, берәм-сәрәм,елдан-ел*

**Тезмә рәвешләр:** *ике яклап, яшь көенчә, чамадан тыш, яшь көйгә, биш былтыр, чын күңелдән, бу юлы*

## Рәвешләрне тикшерү

**Анализ ясау тәртибе**

1. Сүз төркеме билгеләнә.
2. Мәгънә төркемчәсе күрсәтелә.
3. Исемләшкәндә, саны, тартым белән төрләнү- төрләнмәве, килеше билгеләнә.
4. Нинди җөмлә кисәге булуы әйтелә.
5. Ясалышы буенча төре күрсәтелә.

Күлгә ***якынрак*** агачлар тагы да юанрак шәүләләр ташладылар.

**Якынрак**-урын рәвеше, чагыштыру дәрәҗәсендә, *кайсы агачлар?* соравына җавап бирә, җөмләдә аергыч булып килгән, тамыр сүз.

Мин ***күп*** күрдем ***филдәй*** кешеләрне, киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
**Күп**-күләм-чама рәвеше, *ничаклы? күпне күрдем?* соравына җавап бирә, җөмләдә күләм хәле булып килгән, тамыр сүз.
**филдәй**-охшату-чагыштыру рәвеше, *нинди кешеләрне?* соравына җавап бирә, җөмләдә аергыч булып килгән, ясагыч кушымча ялганып ясалган ясалма сүз.

## Рәвеш темасы буенча тестлар

**1. Рәвеш нинди сүз төркеменә керә?**

а) мөстәкыйль сүз төркеменә

ә) модаль сүз төркеменә

б) бәйләгеч сүз төркеменә.

**2. Рәвеш лексик- грамматик яктан нәрсәне белдерә?**

а) предметны белдерә

ә) хәрәкәтне

б) эш яки хәлнең билгесен

в) предметның билгесен.

**3. Морфологик яктан рәвешнең төп характерлы үзенчәлеге нинди?**

а) төрләнми

ә) төрләнә

**4. Рәвеш кайчан сыйфатны ачыклап килә?**

а) предметның билгесен белдергәндә

ә) билгенең билгесен белдергәндә

б)эш яки хәлнең билгесен белдергәндә

**5. Нинди мәгънә белдерүенә карап, рәвешләрнең төркемчәсен билгеләгез.**

Күп, аз, шактый, бертуктаусыз, бераз, кич

а) саф рәвешләр

ә) урын рәвешләре

б) күләм-чама рәвешләре

**6. Бирелгән рәвешләрнең төркемчәсен күрсәтегез.**

Мамыктай, кушканча, ишетелгәндәй, яшьләрчә, үзенчә.

а) вакыт рәвешләре

ә) охшату-чагыштыру рәвешләре

б) саф рәвешләр

**7. Рәвешләрнең төркемчәсен күрсәтегез.**

Салмак, әкрен, тиз, җәяү, кинәт, аягүрә, яланаяк, ашык-пошык.

а) саф рәвешләр

ә) урын рәвешләре

б) сәбәп-максат рәвешләре

**8. Бу рәвешләр кайсы төркемчәгә керә?**

Юри, бушка, тикмәгә, тиктомалга, әрәмгә.

а) вакыт рәвешләре

ә) сәбәп-максат рәвешләре

б) саф рәвешләр

**9. Бу рәвешләр кайсы төркемчәгә керә?**

Ерак, югары, түбән, анда, монда, ары, бире, якын

а) урын рәвешләре

ә) охшату-чагыштыру рәвешләре

б) сәбәп-максат рәвешләре

1 нче вариант

1.Рәвеш дип нинди сүз төркеменә әйтәбез? Ул кайсы сүз төркемнәрен ачыклап килә? Җавап яз, мисаллар китер.

2. Түбәндәге рәвешләрне төркемчәләргә аерып язарга . Һәр төркемчәдән 1 рәвеш белән җөмлә төзергә: **кинәт, иртән, татарча, бераз, күп, аз, салмак, бирелә, юри, югарыда, ерак, тиктомалга, юктан, уттай, шактый, берьюлы, быел, ары, акчалата, байтак, кышын.**

3. Рәвешләрне сүз төркеме буларак тикшерергә: Январьда аяз көннәр **сирәк** була. **Кышын** бураннар **берөзлексез** дәвам итә.

2 нче вариант

1. Рәвешләр мәгънәләре буенча нинди төркемчәләргә бүленәләр? Җавап яз, кимендә 4әр мисал китер.

2. Рәвешләр нинди җөмлә кисәкләре булып килә? Җавап яз, мисаллар китер.

3. Рәвешләрне сүз төркеме буларак тикшерергә:

***Кичкырын кинәт*** буран чыкты. Биргәнгә биш тә ***күп***, алганга алты да ***аз***.

3 нче вариант

1.Төзелеше буенча рәвешләр нинди булалар? Җавап яз, мисаллар китер.

2.Рәвешләрне төркемчәләргә аерып язарга, һәр төркемчәдән 1 рәвеш белән җөмлә төзергә: кышын, бераз, тиккә, атналап, яшьләрчә, галәмәт, якын, түбәндә, бертавыштан, салмак, уттай, элек, берникадәр, аягүрә, бая, аз, уңда, биредә, юктан гына, беррәттән, ерак.

3.Рәвешләрне сүз төркеме буларак тикшерергә:
Һава ***бераз*** салкынча. ***Якын*** авыллардан кешеләр ***җәяү*** килделәр.

4 нче вариант

1.Рәвешләр җөмләнең кайсы кисәкләре булып киләләр? Җавап яз,  мисаллар  китер

2.Түбәндәге рәвешләрне төркемчәләргә  аерып яз, һәр төркемчәдән 1 рәвеш   белән җөмлә төзеп яз: **ифрат, бушлай, төнлә, көнозын, тиктомалга, түбәндә, быел,ерак, кызу, көзгедәй, потлап, якын, уңда, соң, уйлаганча, юри, бушка, яланөс, кичкырын, шактый, бөтенләй, югарыда, бераз, кышын.**

3. Рәвешләрне табарга, сүз төркеме буларак тикшерергә:

Ул өйрәнчегенең уңышына ***аталарча*** шатланды. Яшь хатын, елап, кабер  өстенә ***йөзтүбән*** капланды. ***Күпне*** күргән егет ул.

5 нче вариант

1.Түбәндәге сүзләрдән рәвешләр ясап язарга**: акча, ата, атна, көмеш, кол, китап, кыш, әйбер.**

2.Рәвешләр мәгънәләре буенча нинди төркемчәләргә бүленәләр? Җавап яз,мисаллар китер.

3.Рәвешләрне табарга , сүз төркеме буларак тикшерергә:
Әнә ***ерракта*** урман күренә. Җәнлекләр өчен әле азык ***күп***.
***Иртән*** һәм ***кичен*** көннәр салкынча.

6 нчы вариант

1. Нинди сүз төркеме рәвеш дип атала? Җавап яз, мисаллар китер.

2. Төзелешләре буенча рәвешләр нинди булалар? Мисаллар яз.

3. Рәвешләрне табарга, сүз төркеме буларак тикшерергә.
Башта сине ***озак*** көттем. Ул улын ***аталарча*** кайгыртты, аны ***бик*** яратты.

7 нче вариант

1. Рәвеш җөмләнең нинди кисәкләре була? Җавап яз, мисаллар китер.

2. Түбәндәге рәвешләр белән җөмләләр уйлап яз: **галәмәт, мамыктай, көзен, юри, башма-баш.**

3. Рәвешләрне сүз төркеме буларак тикшер.

***Җәен*** тургай ***ифрат*** күп эшли**.** Бер оя баланы ***күз карасыдай*** карап үстерә.

8 нче вариант

1. Рәвеш төркемчәләрен санап, һәрберсенә мисаллар яз.

2. Түбәндәге сүзләрдән рәвешләр яса, өчесе белән җөмлә төзе: **кояш, акча, атна, дуслар, бер, баш**.

3.Рәвешләрне сүз төркеме буларак тикшер.

Алар ***хәзер*** вакытны ***сәгатьләп*** исәпләделәр. Эшне ***ифрат*** кызу тоттылар.